**ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ЗАКУПКАМ**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ САТЫП АЛУЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ**

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

24.04.2023 № 09-05-52

Казан шәһәре

Татарстан Республикасының Сатып алулар буенча дәүләт комитетында вазифа биләү ришвәтчелек куркынычлары белән бәйле булган, вазифа биләгәндә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре үзләренең керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәткә бәйле бурычлары турында белешмәләр, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәткә бәйле бурычлары турында белешмәләр тапшырырга тиешле Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазифалары исемлеген раслау хакында

2008 нче елның 25 нче декабрендә кабул ителгән “Ришвәтчелеккә каршы көрәш турында” 273-ФЗ номерлы Федераль законын, Татарстан Республикасы Президентының 2010 нчы елның 30 нчы сентябрендә чыгарылган “Ришвәтчелеккә каршы көрәш турында” Федераль Законының кайбер нигезләмәләрен тормышка ашыру чаралары турында” УП-636 номерлы Указын, Татарстан Республикасы Президентының 2009 нчы елның 30 нчы декабрендә чыгарылган “Вазифа биләгәндә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре үзләренең керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәткә бәйле бурычлары турында белешмәләр, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәткә бәйле бурычлары турында белешмәләр тапшырырга тиешле Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазифалары исемлеген раслау турында” УП-701 номерлы Указын, Татарстан Республикасы Президентының 2009 нчы елның 30 нчы декабрендә чыгарылган “Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазифаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнарның керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәткә бәйле бурычлары турында белешмәләр, шулай ук Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәткә бәйле бурычлары хакында белешмәләр бирү турында” УП-702 номерлы Указын үтәү йөзеннән б о е р ы к  б и р ә м:

1. Татарстан Республикасының Сатып алулар буенча дәүләт комитетында вазифа биләү ришвәтчелек куркынычлары белән бәйле булган, вазифа биләгәндә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре үзләренең керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәткә бәйле бурычлары турында белешмәләр, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәткә бәйле бурычлары турында белешмәләр тапшырырга тиешле Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазифалары исемлеген расларга.

2. Кадрлар эшен оештыру һәм алып бару өчен җаваплы хезмәткәргә:

Исемлеккә кертелгән вазифаларны биләгән дәүләт граждан хезмәткәрләренә, аларны эштән чыгарганда, 2008 нче елның 25 нче декабрендә кабул ителгән “Ришвәтчелеккә каршы көрәш турында” 273-ФЗ номерлы Федераль законның 12 нче маддәсендә каралган чикләүләрне, бурычларны һәм җаваплылыкны аңлатырга;

бу боерыкны Исемлеккә кертелгән вазифаларны биләүче дәүләт граждан хезмәткәрләренә җиткерергә.

3. Татарстан Республикасының Сатып алулар буенча дәүләт комитетының 2017 нче елның 5 нче июнендә язылган “Татарстан Республикасының Сатып алулар буенча дәүләт комитетында вазифа биләү ришвәтчелек куркынычлары белән бәйле булган, вазифа биләгәндә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре үзләренең керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәткә бәйле бурычлары турында белешмәләр, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәткә бәйле бурычлары турында белешмәләр тапшырырга тиешле Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазифалары исемлеген раслау хакында” 04-14-76 номерлы боерыгын гамәлдән чыккан дип танырга.

4. Әлеге боерыкның үтәлешен үзем контрольдә тотачакмын.

Рәис Р.Н.Сабиров

Татарстан Республикасының Сатып алулар буенча дәүләт комитетының 2023 нче елның 24 нче апрелендә чыгарылган 09-05-52 номерлы боерыгы белән расланган

Татарстан Республикасының Сатып алулар буенча дәүләт комитетында вазифа биләү ришвәтчелек куркынычлары белән бәйле булган, вазифа биләгәндә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре үзләренең керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәткә бәйле бурычлары турында белешмәләр, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәткә бәйле бурычлары турында белешмәләр тапшырырга тиешле Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазифалары исемлеге

Җитәкчелек

1. Рәис урынбасары

Үзәкләштерелгән сатып алуларны анализлау һәм тәэмин итү бүлеге

2. Бүлек башлыгы
3. Бүлек башлыгы урынбасары
4. Әйдәп баручы киңәшче
5. Әйдәп баручы белгеч
6. 1 нче разрядлы өлкән белгеч

Дәүләт контрактларын үтәү бүлеге

7. Бүлек башлыгы
8. Әйдәп баручы киңәшче
9. Әйдәп баручы белгеч
10. 1 нче разрядлы өлкән белгеч

Сатып алуларны методик тәэмин итү бүлеге

11. Бүлек башлыгы
12. Әйдәп баручы киңәшче
13. Әйдәп баручы белгеч

Үзәкләштерелгән сатып алулар бүлеге

14. Бүлек башлыгы
15. Бүлек башлыгы урынбасары

16. Әйдәп баручы киңәшче
17. Әйдәп баручы белгеч
18. 1 нче разрядлы өлкән белгеч

Бүлектән тыш дәүләт граждан хезмәткәрләре

19. Әйдәп баручы киңәшче
20. Әйдәп баручы белгеч